РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

улица Бебеля, дом 129,
город Чистополь, 422980

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

Бебель урамы, 129 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел. (84342) 5-43-60, тел/факс 5-43-70, E-mail: chistay@tatar.ru

---

**№ 33/3** **2018 елның 19 апреле**

***Решение*** ***Карар***

Җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләренең бер өлешен кабул итәргә:
- күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өлешендә муниципаль торак фондын тоту;
- шәһәр халкына китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру һәм Чистай шәһәре халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү.

2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетына:

Чистай шәһәр башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә, төзелә торган килешүләрнең гамәлдә булуы 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагылуын исәпкә алып;

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне билгеләнгән тәртиптә тапшыру турындагы килешүне имзалаганнан соң бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
башлыгы вазыйфаларын башкаручы Р.Г. Хаматов